Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Башкарма комитеты

КАРАР

23 январь 2024 ел №1

Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар,«Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Әлмәт районында 2024 елның 18 январендагы 51-34-09/143 номерлы клиентлар хезмәте мөрәҗәгате (бүлек хокуклары) нигезендә

Рус Акташы авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 01 февраленнән Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясенд җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталар гаярашлырәвештә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтел торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында» 2023 елның 27 январендагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Рус Акташи авылы, Төзүчеләр урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы ның рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз емдә калдырам.

Рус Акташы авыл Башкарма комитеты җитәкчесе С.А.Белоногов

Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Башкарма
комитетының 2024 елның «23
январендәге 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән
исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү ләрөчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 4 873,92 |
| 3 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәмкүмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Рус Акташы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.А.Белоногов

Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Башкарма
комитетының 2024 елның
«23»январендәге 1
номерлы карарына 2 нче
кушымта

Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү ләрөчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гәүдәне төрү | 2 857,57 |
| 3 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 2 016,35 |
| 4 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәмкүмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Рус Акташы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.А.Белоногов